**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**28 ноябрь 2020 ел** **№2**

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Урманай т. п. мөселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, киртәләр кую);
- Мөселман зиратын карап тору (тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу);
- Зиратларны коймалау өчен материаллар сатып алу, Урманай торак пунктында меселман зираты коймаларын ясау һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара елкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Авыл җирлеге территориясен тезекләндерүне оештыру (Урманай авылындагы ике телдә урам исемнәре һәм йортлар язылган күрсәткечләр сатып алу(әзерләү);
- Урманай авылында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге башлыгы А.И.Закиров